**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүне камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 26 декабрендәге ПУ-1277 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 15 гыйнварындагы ПУ-6 номерлы, 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-911 номерлы, 2017 елның 27 июлендәге ПУ-660 номерлы һәм 2019 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 27 октябрь
№ ПУ-828

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «27» октябрендәге
ПУ-828 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – дәүләт хезмәте) дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартларын, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны уздыру тәртибенә таләпләр, әлеге Административ регламентны үтәүне контрольдә тоту рәвешләре, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының (алга таба шулай ук – Министрлык), аның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе билгеләнә.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар – дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) белән Министрлыкка мөрәҗәгать иткән физик затлар яисә юридик затлар (алга таба – гариза бирүче) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре (алга таба – гариза бирүченең вәкиле).

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлык, аның структур бүлекчәләре турында белешмә мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://minleshoz.tatarstan.ru), «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Республика порталы) (uslugi.tatar.ru), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (www.frgu.gosuslugi.ru), «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал) урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматлар кертелгән дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмати элмә такталардан;

2) «Интернет» челтәреннән:

Министрлыкның рәсми сайтында;

Республика порталында;

Бердәм порталда;

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.5. Министрлыкның рәсми сайтында, Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмати элмә такталарда, Республика порталында, Бердәм порталда гариза бирүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү максатында түбәндәге белешмәләр урнаштырыла:

1) дәүләт хезмәтенең атамасы;

2) гариза бирүчеләрнең исемлеге;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, әлеге документларны тутыруга таләпләр;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү барышында тормышка ашырылган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерү хокукы турында мәгълүмат;

7) Министрлыкның эш вакыты, Министрлык белгечләренең дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча кабул итү графигы турында мәгълүмат.

Министрлыкның рәсми сайтында һәм Республика порталында әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүмат Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Министрлык күрсәтелгән мәгълүматның вакытында яңартылып торуын тәэмин итә.

1.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми рәвештә бастыру чыганакларын күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәм порталда, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы: урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы структур бүлекчә – Министрлыкның аренда мөнәсәбәтләре бүлеге (алга таба – Бүлек).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында Министрлык түбәндәге оешмалар белән хезмәттәшлек итә:

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаменты;

Балыкчылык буенча федераль агентлыкның Урта Идел территориаль идарәсе;

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты;

Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;

Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре – урманчылыклар (алга таба – урманчылыклар).

2.4. Гариза бирүчегә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелган урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен арендалау шартнамәсе проектын яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турындагы карарны җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып тора.

2.5. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте түбәндәге юллар белән күрсәтелә:

1) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гаризаны Министрлыкка шәхсән үзе, почта яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге (алга таба – күпфункцияле үзәк) аша биргәндә;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү барышы һәм гариза бирүче шәхсән үзе кәгазь чыганакта килеп алсын өчен аның нәтиҗәсе әзер булуы турында язмача хәбәрнамә җибәрелә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе гариза бирүчегә шәхсән тапшырыла яисә почта аша, аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәлгән заказлы хат рәвешендә кәгазь чыганакта җибәрелә;

2) гаризаны Республика порталы яисә Бердәм портал аша биргәндә:

гариза бирүчегә, аның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кайсы портал аша мөрәҗәгать итүенә бәйле рәвештә, Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы шәхси кабинетында дәүләт хезмәте күрсәтүне карап тикшерү барышы һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең әзер булуы турында хәбәрнамә җибәрелә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе электрон документ рәвешендә гариза бирүченең Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә;

гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алуны сайлаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе гариза бирүчегә шәхсән тапшырыла яисә почта аша, аңа тапшырылу турында хәбәрнамә теркәп, заказлы хат рәвешендә җибәрелә.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты Министрлыкка гариза кергән көннән 15 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына түбәндәгеләр керә:

1) урман кишәрлеген арендага бирү турында гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү – гариза кергән көннән бер эш көне;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) аша ведомствоара сорату һәм язмача сорату формалаштыру һәм җибәрү – гариза теркәлгән көннән бер эш көне;

3) урман кишәрлеген арендага бирү турында яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар кабул итү – ВЭХС аша документлар (мәгълүматлар) алынган көннән биш эш көне;

4) урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсе проектын әзерләү, аңа кул кую һәм гариза бирүчегә җибәрү – урман кишәрлеген арендага бирү турында карар кабул ителгән көннән дүрт эш көне.

2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән мөнәсәбәтләр Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәм порталда, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына.

2.8. Дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге:

1) әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча министр исеменә гариза, анда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

а) Россия Федерациясе Урман кодексының $73^{1}$ статьясы 3 кисәге нигезендә урман кишәрлеген арендалау турында гариза биргәндә:

юридик зат өчен – оешманың атамасы, банктагы реквизитлары;

физик зат өчен – гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (вакытлыча яшәү урыны) адресы, шәхесен таныклаучы документ реквизитлары;

арендалау күздә тотылган урман кишәрлегенең урнашкан урыны һәм мәйданы;

арендалау күздә тотылган урман кишәрлегеннән файдалануның максаты, төре (төрләре) һәм вакыты;

урман кишәрлегенең кадастр номеры;

урман кишәрлегенең проект документларын раслау турында карарның, соралган урман кишәрлеге әлеге карар нигезендә булдырылган яисә чикләре анықланган очракта, реквизитлары;

гариза бирүченең почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы, шулай ук телефон номеры (номерлары);

дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алу юллары;

б) Россия Федерациясе Урман кодексының 74 статьясы 1 кисәге нигезендә урман кишәрлеген арендалау өчен яңа шартнамә төзү турында гариза биргәндә:

юридик зат өчен – оешманың атамасы, банктагы реквизитлары;

физик зат өчен – гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (вакытлыча яшәү урыны) адресы, шәхесен таныклаучы документ реквизитлары;

элек төзелгән арендалау шартнамәсенең номеры һәм аңа кул кую датасы (шул исәптән арендалау шартнамәсен дәүләт теркәвенә алу датасы), аның гамәлдә булу вакыты, урманнардан файдалану төре (төрләре), урман кишәрлегенең кадастр номеры;

яңа арендалау шартнамәсе гамәленең фаразланган вакыты;

гариза бирүченең почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы, шулай ук телефон номеры (номерлары);

дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алу юллары;

2) гариза бирүче гаризаны Министрлыкка шәхсән үзе, почта аша яисә күпфункцияле үзәк аша биргәндә – әлеге Административ регламентның 2 номерлы кушымтасы нигезендәге форма буенча шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (физик затлар өчен);

3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гаризаның бланкын гариза бирүче Министрлыкка, күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәй порталда урнаштырыла.

Гариза һәм аңа теркәп бирелүче документлар гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) тарафыннан түбәндәге юллар белән бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ нигезендә гариза бирүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан);

почта аша;

күпфункцияле үзәк аша;

гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап кайсы портал аша мөрәҗәгать итүенә бәйле рәвештә, Бердәм порталны яисә Республика порталын файдаланып.

2.9. Гариза бирүче теләгән очракта түбәндәге документларны бирергә хокуклы:

юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта – юридик затның Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән булуын раслау өчен Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматларны;

шәхси эшкуар мөрәҗәгать иткән очракта – шәхси эшкуарның Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән булуын раслау өчен Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматларны;

салым органында салым түләүче буларак теркәлү турында мәгълүматны;

реконструкцияләнергә тиешле объектларга (урман кишәрлекләрен линия объектлары төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен арендага биргәндә) хокукны билгели яисә хокукныраслый торган документларның булуы турында мәгълүмат;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең булуы турында мәгълүмат (урман кишәрлекләрен җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен арендага биргәндә);

урманнардан файдалану өлкәсендә инвестиция проектларының өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә кертелүен раслаучы документлар турында мәгълүмат (урман кишәрлекләрен урманнардан файдалану өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында арендага биргәндә);

аучылык хуҗалыклары төзегән килешүләр турында мәгълүмат;

урман кишәрлегендә урнашкан бињалар, корылмалар, алардагы бүлмәләргә хокукны раслаучы документларның реквизитлары яисә әлеге объектларда хуҗалык эшчәнлеге алып баруга яисә аларга оператив идарәгә хокукны раслый торган документларның реквизитлары (Россия Федерациясе Урман кодексының 73[1] статьясы 3 кисәге 4 пункты нигезендә урман кишәрлекләрен арендага биргәндә).

Документларны тапшыру ысуллары әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында билгеләнгән.

Гариза бирүче тарафыннан әлеге документларның бирелмәве гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Министрлык түбәндәгеләрне соратып ала:

1) Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән:

юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта – юридик затның Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән булуын раслау өчен Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматларны;

шәхси эшкуар мөрәҗәгать иткән очракта – шәхси эшкуарның Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән булуын раслау өчен Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматларны;

салым органында салым түләүче буларак теркәлү турында мәгълүматны;

2) Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән:

реконструкцияләнергә тиешле объектларга (урман кишәрлекләрен линия объектлары төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен арендага биргәндә) хокукны билгели яисә хокукны раслый торган документларның булуы турында мәгълүматны;

урман кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар, алардагы бүлмәләргә хокукны раслый торган документларның реквизитлары яисә әлеге объектларда хуҗалык эшчәнлеге алып баруга яисә аларга оператив идарәгә хокукны раслаучы документларның реквизитлары (Россия Федерациясе Урман кодексының 73[1] статьясы 3 кисәге 4 пункты нигезендә урман кишәрлекләрен арендага биргәндә);

3) Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча Идел буе федераль округы буенча департаменттан:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең булуы турында мәгълүматны (урман кишәрлекләрен җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару, файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү өчен арендага биргәндә);

4) Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгыннан:

урманнардан файдалану өлкәсендә инвестиция проектларын өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә кертүне раслый торган документлар турында мәгълүматны (урман кишәрлекләрен урманнардан файдалану өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында арендага биргәндә);

5) Балыкчылык буенча федераль агентлыкның Урта Идел территориаль идарәсеннән:

балык үрчетү участогыннан файдалану шартнамәсе турында мәгълүматны;

6) Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетыннан:

аучылык хуҗалыклары төзегән килешүләр турында мәгълүматны;

7) арендага бирелә торган урман кишәрлеге урнашкан ведомство карамагындагы территориядәге урманчылыктан:

урман кишәрлеген арендага алу шартнамәсенә кушымталарны.

2.11. Әлеге Административ регламентның 2.10 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарының һәм оешмаларның документларны һәм мәгълүматны бирмәве (вакытында бирмәве) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлыкка гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, әлеге Административ регламентта бирү каралмаган документларны яисә мәгълүматны бирүне яки гамәл кылу каралмаган гамәлләр кылуны;

2) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 6 кисәгендә (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) күрсәтелгән документлардан кала, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт хакимияте органнары, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм (яисә) оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматны бирүне;

3) түбәндәге очраклардан кала, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгать беренче тапкыр кире кагылганда аларның булмавы һәм (яисә) төгәл булмавы билгеләнмәгән документларны һәм мәгълүматны бирүне:

дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап беренче тапкыр гариза биргәннән соң норматив хокукый актларда дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы таләпләрнең үзгәрүе;

гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә мөрәҗәгате беренче тапкыр кире кагылганнан соң гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап язган гаризасында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле элек бирелгән документлар тупланмасына кертелмәгән документларда хаталарның булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать кире кагылганнан соң документларның гамәлдә булу вакыты чыгуы яисә мәгълүматның үзгәрүе;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать беренче тапкыр кире кагылган вакытта Министрлыкның вазыйфаи затының документлар нигезендә расланган хаталы яисә законга каршы гамәлләр кылу (гамәл кылмау) факты (билгеләре) ачыклануы һәм, гариза бирүчедән аңа уңайсызлыклар китергән өчен гафу үтенеп, бу турыда гариза бирүчегә язма рәвештә Министрлык җитәкчесе имза куйган хәбәр җибәрелә;

4) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы 1 кисәгендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәсендә хезмәт күрсәтүләр, документлар һәм мәгълүмат алудан тыш, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле булган һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләр кылу, шул исәптән килештерү узу;

5) әлеге документларга тамгалар кую яисә аларны кире алу дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле шарт булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш, электрон үрнәкләре «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 кисәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк расланган документларны һәм мәгълүматны кәгазь чыганакта бирү.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

1) гариза бирүче дәгъва кылган урман кишәрлегенә карата өченче затларның хокукы булуы (Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясы 2 кисәгендә каралган очраклардан, шулай ук юридик затларга яисә шәхси эшкуарларга урманнарны Россия Федерациясе Урман кодексының 43–46 статьялары нигезендә файдалану өчен биргәндә, әлеге урман кишәрлекләрендә үзагач әзерләү очракларыннан тыш);

2) төгәл яки тулы булмаган яисә әлеге Административ регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән документлар бирү;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге урман кишәрлегендә урманнардан файдалануның гаризада билгеләнгән төрен башкаруның тыелуы;

4) урманнардан файдалануның гаризада билгеләнгән максаты (максатлары) Татарстан Республикасы Урман планына яисә урманчылыкның (урман паркының) урман хуҗалыгы регламентына туры килмәве;

5) арендага алу турында гаризада күрсәтелгән урман кишәрлегенең мәйданы территорияне межалау проектында һәм әлеге кишәрлек булдырылган урман кишәрлеген проектлау документларында күрсәтелгән мәйданыннан кимендә ун процентка зуррак булуы;

6) Россия Федерациясе Урман кодексының 47 статьясы 1 кисәге нигезендә урман кишәрлеген арендага биргән очракта – Россия Федерациясе Урман кодексының 74 статьясы 2 кисәгендә каралган шартларның берсе генә булса да үтәлмәве.

2.15. Дәүләт хезмәтен гариза кергәнчегә кадәр алдан әзерләү (проактив) режимында күрсәтү очраклары булганы юк.

2.16. Дәүләт хезмәте өчен түләү алынмый.

2.17. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелүче документ (документлар) турында мәгълүматлар Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралмаган.

2.18. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү әлеге хезмәтләрнең булмавы сәбәпле алынмый.

2.19. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза биргән вакытта, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда Министрлыкта һәм күпфункцияле үзәктә чират көтү вакыты 15 минуттан та артырга тиеш түгел.

2.20. Эш көнендә 18:00 гә кадәр бирелгән гариза Министрлыкта кергән көнендә теркәлә. Эш көнендә 18:00 дән соң яисә эш көне булмаган көнне бирелгән гариза Министрлыкта икенче эш көнендә теркәлә.

2.21. Гариза бирүчеләр белән эшләү биналарында дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүмат бирелгән элмә такталар куела. Бинаның ал ягында Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең атамасы турында мәгълүмат урнаштырыла.

Гариза бирүчеләргә документлар тутыру өчен урындыклар, өстәлләр куелган кабул итүне көтү урыннары бүлеп бирелә.

Бина санитар таләпләргә һәм нормаларга туры китереп җиһазландырылырга тиеш.

Министрлык, күпфункцияле үзәк инвалидлар (кресло-коляскадан һәм юл күрсәтүче этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) өчен түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

гариза бирүчеләр белән эшләү биналарына тоткарлыксыз керү өчен шартлар булдыруны;

гариза бирүчеләр белән эшләү биналары урнаштырылган территориядә мөстәкыйль хәрәкәт итү, әлеге биналарга керү һәм алардан чыгу, шул исәптән кресло-коляска файдаланып, транспортка утыру һәм аннан чыгу өчен мөмкинлекләрне;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү сәләте ягыннан дәвалап булмый торган авырулары булган инвалидларны озатып йөрүне, аларга ярдәм итүне;

инвалидларның тормыш эшчәнлегенә кагылышлы чикләүләрне исәпкә алып, аларның гариза бирүчеләр белән эшләү биналарына тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазлар һәм мәгълүмат чыганаклары урнаштыруны;

инвалидлар өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә бирелә һәм укыла торган мәгълүматны һәм шулай ук язмаларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм графикалы мәгълүматны рельеф-нокталы Брайль шрифты белән язылган билгеләр ярдәмендә кабатлап бирүне, бинага сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертүне;

гариза бирүчеләр белән эшләү бинасына, аның махсус өйрәтелгән булуын раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Юл күрсәтүче этнең махсус өйрәтелгән булуын һәм аны бирү тәртибен раслый торган документ формасын раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы карары нигезендә расланган форма һәм тәртип буенча бирелә торган документ булганда, юл күрсәтүче этне кертүне;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең инвалидларның башка затлар белән бер дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалана алуына комачаулык итүче киртәләрне узуда ярдәм итүен.

Гариза бирүчеләр белән эшләү биналарын инвалидлар мәнфәгатьләрен исәпкә алып тулысынча үзгәртеп кору мөмкин булмаганда, әлеге затлар дәүләт хезмәте күрсәтү урынына әлеге мөмкинлек булдырылгач, үзенең тору урыны буенча килә ала яки дистанцион режимда тәэмин ителә.

Министрлык, күпфункцияле үзәк бинасы янындагы территория транспорт кую өчен урыннар белән җиһазландырыла.

2.22. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу һәм аның сыйфатлы булуы дәрәҗәсе түбәндәгеләр нигезендә бәяләнә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында гражданнарның хәбәрдар булуы дәрәҗәсе (дәүләт хезмәте турында мәгълүматның ачыклыгы, мәгълүмат алу ысулын сайлау мөмкинлеге);

2) Бердәм портал яисә Республика порталы аша электрон рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге;

3) дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен түләүсез рәвештә Бердәм порталга яисә Республика порталына керү мөмкинлеген тәэмин итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү срокларының һәм дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта административ процедуралар срокларының үтәлүе;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрдән нигезле шикаятьләрнең булмавы;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итү.

Гариза бирүчеләргә Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу дәрәҗәсен һәм аның сыйфатлы булуын бәяләү мөмкинлеге бирелә.

2.23. Гариза бирүче Министрлыкның вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә:

1) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны шәхсән (гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ нигезендә гариза бирүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан) тапшырганда – 15 минуттан да артык түгел;

2) шәхсән (гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ нигезендә гариза бирүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда, шулай ук Республика порталы яисә Бердәм портал ярдәмендә мөрәҗәгать иткән гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алу ысулын сайлаганда – 15 минуттан да артык түгел.

Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны шәхсән (гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ нигезендә гариза бирүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан) биргәндә, Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять биргәндә – 15 минуттан да артык түгел.

2.24. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны Министрлыкка телдән (шәхсән яисә телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтыннан, Республика порталыннан, Бердәм порталдан алырга була.

2.25. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза белән күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гариза кергәч, күпфункцияле үзәк күпфункцияле үзәк һәм Министрлык арасында хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин

гариза күпфункцияле үзәккә кергән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча, аның Министрлыкка тапшырылуын тәэмин итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза күпфункцияле үзәккә бирелгән очракта, дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

Комплекслы сорату буенча дәүләт хезмәте күрсәтү каралмаган.

2.26. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәгеләр тормышка ашырыла:

1) гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) әлеге Административ регламентта билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат бирү һәм гариза бирүченең (гариза бирүчеләр вәкиленең) дәүләт хезмәте турында мәгълүматлардан файдалана алуын тәэмин итү;

2) гариза бирүченең кайсын сайлавына карап, Бердәм портал һәм Республика порталы аша, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә Министрлыкка җибәрү;

3) ВЭХС аша яисә язмача соратулар җибәрү юлы белән Министрлыкның һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче башка органнарның, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт хакимияте органнары һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеге;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә соратуны үтәүнең барышы турында мәгълүмат алуы;

5) гариза бирүче Бердәм портал һәм Республика порталындагы шәхси кабинетында дәүләт хезмәте күрсәтүнең Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куйган нәтиҗәсен алуы;

6) әлеге Административ регламентның V кисәгендә билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү.

2.27. Гариза бирүче Бердәм портал яисә Республика порталы аша электрон рәвештә гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

1) гамәл кылуга хокукын раслый;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри мәгълүматлардан торган электрон гариза формасын ача һәм тутыра;

3) электрон гариза формасына электрон рәвештәге документларны яисә документларның электрон нөсхәләрен беркетә;

4) электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын, шулай ук шәхси белешмәләрне эшкәртүгә килешүне (физик затлар өчен, шәхси эшкуарларны да кертеп) раслый;

5) хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый;

6) әлеге Административ регламент таләпләренә туры китереп, электрон гаризага имза куя;

7) тутырылган электрон гаризаны җибәрә һәм аның җибәрелүе расланган тиешле хәбәр ала.

2.28. Бердәм порталда яисә Республика порталында гариза бирүчегә тутыру өчен гаризаның электрон формасы урнаштырыла. Гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасының һәр юлы тутырылганнан соң, аның бердәй электрон сервис форматына туры килү-килмәве тикшерелә. Гаризаның электрон формасында юлларның тиешенчә тутырылмавы ачыкланган очракта, гариза бирүчегә нәкъ менә шушы күрсәтелгән электрон формада нинди хата китүе һәм аны төзәтү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр бирелә.

2.29. Документларны электрон рәвештә тапшырганда гариза бирүчегә түбәндәге мөмкинлекләр бирелә:

1) элегрәк кертелгән мәгълүматны саклаган хәлдә, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына әйләнеп кайту;

2) гариза бирүченең Бердәм порталда һәм Республика порталында элегрәк аның тарафыннан тапшырылган документлардан, әлеге документлар тапшырылган вакыттан кимендә бер ел дәвамында файдалана алуы.

2.30. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризага гариза бирүченең яисә аның вәкиленең гади электрон имзасы яисә урман кишәрлеген арендага бирү турында шартнамәгә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куела.

## III. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, башкару эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкаруның үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедуралардан тора:

урман кишәрлеген арендага бирүгә гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

ВЭХС аша дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы дәүләт хакимияте органнарына ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү һәм ВЭХС аша документларны (мәгълүматларны) алу;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан урман кишәрлеген арендага бирү яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар кабул ителү;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгының урман кишәрлеген арендага бирү турында боерыгын бастырып чыгару яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар кабул ителү;

урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсе проектын әзерләү, аңа кул кую һәм аны гариза бирүчегә җибәрү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда ясалган хәреф хаталарын һәм ялгышларны төзәтү.

**Урман кишәрлеген арендага бирүгә гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү**

3.2. Урман кишәрлеген арендага бирүгә гаризаның һәм документларның Министрлыкка керүе административ процедураларны (гамәлләрне) башлау өчен нигез булып тора.

3.3. Административ процедураны (гамәлләрне) башкару өчен җаваплы зат – Министрлыкның оештыру эше бүлеге башлыгы.

3.4. Гариза бирүче шәхсән яисә үзенең вәкиле ярдәмендә почта, күпфункцияле үзәк аша яисә Республика порталын яки Бердәм порталны файдаланып, электрон документ рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтүгә әлеге Административ регламентының 2.8 пунктында каралган документлар теркәлгән һәм эчтәлеге әлеге Административ регламентның таләпләренә туры килгән гариза бирә.

Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләре билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелергә тиеш.

3.5. Министрлыкның оештыру эше бүлеге белгече гариза кергән көнне түбәндәгеләрне башкара:

1) гаризаны һәм бирелгән документларны терки;

2) Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы һәм гаризаның аны кабул итү номеры куелган күчермәсен бирә;

3) гариза Республика порталы яисә Бердәм портал аша бирелгән очракта, гариза бирүчегә гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәү турында электрон рәвештә хәбәрнамә җибәрелә;

4) бирелгән документларны теркәп, гаризаны министрга җибәрә.

3.6. Административ процедураны (гамәлләрне) башкару нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бирелгән гариза теркәлә, аңа документлар өстәлә, алар министрга җибәрелә.

**ВЭХС аша дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү һәм ВЭХС ярдәмендә документларны (мәгълүматларны) алу**

3.7. Урман кишәрлеген арендага бирү өчен кирәкле документлар җыелмасы белән бергә теркәлгән гаризаның Бүлек башлыгына бирелүе административ процедураны (гамәлләрне) башлау өчен нигез булып тора.

3.8. Административ процедураны (гамәлләрне) башкару өчен җаваплы зат Бүлек башлыгы була.

3.9. ВЭХС аша документлар (мәгълүматлар) алу өчен ведомствоара соратуларны һәм ВЭХС ярдәмендә документларны (мәгълүматларны) Бүлек белгече җибәрә һәм ала.

Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза Министрлыкка шәхсән, почта яисә күпфункцияле үзәк аша гариза җибәрү юлы белән бирелгәндә, ведомствоара сорату гариза теркәлгән көндә әзерләнә һәм җибәрелә.

Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза Республика порталы яисә Бердәм портал аша бирелгәндә, ВЭХС аша ведомствоара сорату, техник мөмкинлекләр булганда, гариза теркәлгән көнне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган автоматлаштырылган мәгълүмат системасы ярдәмендә автомат рәвештә җибәрелә.

Ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасы ярдәмендә ведомствоара соратуга җавап алуның максималь срогы биш эше көне тәшкил итә.

3.10. Әлеге Административ регламентның 2.10 пунктында күрсәтелгән документлар (мәгълүмат) Административ процедураны (гамәлләрне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан урман кишәрлеген арендага бирү яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар кабул ителү**

3.11. Урман кишәрлеге сусаклагычлар яисә башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар, елга портлары, причаллар төзү; юридик затларга, шәхси эшкуарларга аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлекне тормышка ашыру максатларында арендага бирелгәндә – җир кишәрлеген арендага бирү өчен кирәкле документлар тупланмасы белән бергә теркәлгән гаризаның, шулай ук әлеге Административ регламентның 2.10 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарыннан һәм оешмалардан алынган документларның (мәгълүматларның) Бүлек башлыгына бирелүе административ процедураны (гамәлләрне) башлау өчен нигез булып тора.

3.12. Административ процедураны (гамәлләрне) башкару өчен җаваплы зат Бүлек башлыгы була.

3.13. Бүлек белгече ведомствоара соратуларга җаваплар алынган көннән бер эш көне дәвамында:

1) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы 2 кисәге 7 пункты нигезендә урман кишәрлеген арендага бирү яисә урман кишәрлеген арендага бирүнең яңа шартнамәсен төзү турында (алга таба – урман кишәрлеген арендага бирү) тәкъдимнәр әзерли;

2) «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы 2 кисәге 7 пункты нигезендә урман кишәрлеген

арендага бирү турында карар кабул итү өчен документларның бер нөсхәсен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

3.14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Министрлыктан документлар кергән көннән өч эш көне дәвамында урман кишәрлеген арендага бирү турында карар кабул итәр өчен түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) урман кишәрлеген арендага бирү турында;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга әлеге Административ регламентның 2.14 пунктында каралган нигезләр булганда, баш тартуның нигезләрен күрсәтеп, бирелгән документларны Министрлыкка кире кайтара.

3.15. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан бирелгән документлар кире кайтарылган очракта, бүлек белгече Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан бирелгән документлар кире кайтарылган көннән бер эш көне дәвамында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләнгән карар әзерли.

3.16. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан әлеге Административ регламентның 3.14 пунктында күрсәтелгән карарларның берсе кабул ителгән очракта, бүлек белгече гариза бирүчегә урман кишәрлеген арендага бирү яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карарны шәхсән тапшыра яисә гариза бирүчегә, аны алу турында хәбәр белән заказлы хат рәвешендә почта аша, ә дәүләт хезмәте Республика порталы яисә Бердәм портал аша күрсәтелгән очракта, кабул ителгән карарның электрон документын гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрә.

3.17. Гариза бирүчегә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының урман кишәрлеген арендага бирү яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карарын гариза бирүчегә җибәрү административ процедураны (гамәлләрне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

### Урман кишәрлеген арендага бирү турында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгын яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карарны бастырып чыгару

3.18. Урман кишәрлеген җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару, балыкчылык, линия объектлары төзү, аларны реконструкцияләү һәм кулланышка кертү, урманнардан файдалану өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру, юридик затларга яисә шәхси эшкуарларга Россия Федерациясе Урман кодексының 43–46 статьялары нигезендә файдалануга бирелгән урман кишәрлекләрендә үзагач әзерләү максатларында, шулай ук әлеге урман кишәрлегендә булган биналарны, корылмаларны (әлеге бина, корылмадагы бүлмәләрне) әлеге объектларда хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукы булган милек хуҗасына яисә юридик затка арендага бирү өчен

теркәлгән гаризаның һәм урман кишәрлеген арендага алу өчен документларның, шулай ук әлеге Административ регламентның 2.10 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарыннан һәм оешмалардан алынган документларның (мәгълүматларның) Бүлек белгеченә бирелүе административ процедураны (гамәлләрне) башлау өчен нигез булып тора.

3.19. Административ процедураны (гамәлләрне) башкару өчен җаваплы зат Бүлек башлыгы була.

3.20. Бүлек белгече ведомствоара соратуларга җаваплар алынган көннән өч эш көне дәвамында:

1) «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы 3 кисәге 9 пункты нигезендә урман кишәрлеген арендага бирү турында Министрлык боерыгы проектын әзерли һәм аңа кул кую өчен Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затына тапшыра;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Административ регламентның 2.14 пунктында каралган нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар әзерли һәм аңа кул куяр өчен Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затына тапшыра.

3.21. Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты, урман кишәрлеген арендага бирү турында боерык проектын яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын алган көннән бер эш көне дәвамында, урман кишәрлеген арендага бирү турында боерык проектына яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар проектына кул куя һәм Министрлыкның җибәрелә торган корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи затына тапшыра.

3.22. Бүлек белгече урман кишәрлеген арендага бирү яисә урман кишәрлеген арендага бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән бер эш көне дәвамында гариза бирүчегә урман кишәрлеген арендага бирү турында боерыкны яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарны шәхсән тапшыра яисә гариза бирүчегә, аны алу турында хәбәр белән заказлы хат рәвешендә почта аша, ә дәүләт хезмәте Республика порталы яисә Бердәм портал аша күрсәтелгән очракта, кабул ителгән карарның электрон документын гариза бирүченең шәхси кабинетына җибәрә.

3.23. Урман кишәрлеген арендага бирү турында боерыкны яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарны гариза бирүчегә җибәрү административ процедураны (гамәлләрне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

**Урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсе проектын әзерләү, аңа кул кую һәм гариза бирүчегә җибәрү**

3.24. Урман кишәрлеген арендага бирү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын кабул итү, Министрлыкның

боерыгын бастырып чыгару административ процедураны (гамәлләрне) башлау өчен нигез булып тора.

3.25. Административ процедураны (гамәлләрне) башкару өчен җаваплы зат Бүлек башлыгы була.

3.26. Бүлек белгече урман кишәрлеген арендага бирү турында карар кабул ителгән көннән дүрт эш көне дәвамында:

1) урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсе проектын әзерли һәм Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затына кул куярга тапшыра, ул аңа тапшырылган көннән бер эш көне дәвамында кул куярга тиеш;

2) кәгазь чыганакта Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелган урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсе проектының өч нөсхәсен гариза бирүчегә шәхсән тапшыра яисә гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның кайсы ысулын сайлавына бәйле рәвештә, аны алу турында хәбәр теркәлгән заказлы хат рәвешендә почта аша җибәрә;

3) Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаны Республика порталы яисә Бердәм портал аша биргәндә, гариза бирүченең шәхси кабинетына электрон документ рәвешендәге Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсе проекты автомат рәвештә җибәрелә. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алуны сайлаган очракта, әлеге Административ регламентның 3.26 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән административ процедуралар (гамәлләр) башкарыла.

3.27. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаны Республика порталы яисә Бердәм портал аша биргәндә һәм гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен Республика порталындагы яисә Бердәм порталдагы шәхси кабинетында электрон документ рәвешендә алуны сайлаган очракта, гариза бирүче шартнамәгә көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасын куя.

3.28. Урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсе проекты гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсе проекты алынган көннән 10 эш көне дәвамында гариза бирүче тарафыннан кул куелып, почта аша Министрлыкка җибәрелергә яисә ике нөсхәдә шәхси кабул итү вакытында тапшырылырга тиеш.

Гариза бирүченең урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсенә кул куелу һәм җибәрү (тапшыру) вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына керми.

3.29. Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кул куелган урман кишәрлеген арендага бирү шартнамәсен гариза бирүчегә җибәрү административ процедураны (гамәлләрне) башкару нәтиҗәсе булып тора.

## Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү

3.30. Гариза бирүче тарафыннан Министрлыкка дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү турында ирекле шәкелдә язылган гаризаның бирелүе (җибәрелүе) административ процедураны (гамәлләрне) башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү турында гариза Министрлыкка гариза бирүче тарафыннан электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайты, язма рәвештә кәгазь чыганакта почта аша яисә гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә тапшырыла.

3.31. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы Бүлек башлыгы гариза бирүче тапшырган гаризаны карый һәм әлеге гариза теркәлгән көннән ике эш көненнән артык булмаган вакыт эчендә гаризада күрсәтелгән белешмәләрне тикшерә.

3.32. Административ процедура буенча карар хәреф хаталарының һәм (яисә) ялгышларның булуы яки булмавына таянып кабул ителә.

3.33. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталары һәм (яисә) ялгышлар булуы ачыкланган очракта, Бүлек башлыгы тиешле гаризаны теркәгән көннән биш эш көненнән артык булмаган вакыт эчендә күрсәтелгән документлардагы хаталарны төзәтә һәм документларны алмаштыра.

3.34. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталары һәм (яки) ялгышлар булмаган очракта, Бүлек башлыгы гариза бирүчегә язма рәвештә тиешле гариза теркәлгән көннән биш эш көненнән артык булмаган вакыт эчендә әлеге хәреф хаталарының һәм (яисә) ялгышларның булмавы турында хәбәр итә.

3.35. Гариза бирүчегә элек бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка алмашка төзәтелгәнен бирү (җибәрү) яки мондый хаталарның һәм (яки) ялгышларның булмавы турында хәбәр итү административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.36. Әлеге административ процедураны (гамәлләрне) башкару вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына керми.

## IV. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Министрлыктагы вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлеше, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат яки дәүләт

хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.2. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләре үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән алып барыла.

Агымдагы контроль даими нигездә башкарыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүдән, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очракларын ачыклау һәм бетерүдән, гариза бирүчеләрнең Министрлыкның вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләре кертелгән мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүдән, алар буенча карарлар кабул итүдән һәм җаваплар әзерләүдән тора.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү Министрлык актлары нигезендә башкарыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш була ала.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның таләпләре бозылуның элегрәк ачыкланган очракларын бетерүне тикшерү;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмаулары) сәбәпле гражданнар үзләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында шикаять белән мөрәҗәгать итүе.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Контрольдә тоту нәтиҗәләре буенча гариза бирүче хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелүне гариза бирүчеләр тарафыннан контрольдә тоту әлеге Административ регламентта каралган мәгълүматны алу юлы белән, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына), аның тарафыннан кабул ителә торган карарга шикаять бирү юлы белән башкарыла.

## V. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә башкарыла торган һәм әлеге Административ регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның таләпләрен боза торган гамәлләргә (гамәл кылмауларга) һәм карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукына ия.

5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләре (гамәл кылмавы) һәм алар тарафыннан кабул ителгән (башкарыла торган) карарлар судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып тора.

Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

1) гаризаны теркәү срогы үтәлмәү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы үтәлмәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәткәндә аларның тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, әлеге Административ регламентта каралмаган документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4) баш тартуның нигезләре федераль законнарда яисә Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, әлеге Административ регламентта каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәте күрсәткәндә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү өчен каралмаган түләүне гариза бирүчедән таләп итү;

6) Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә әлеге хатларны төзәтү өчен бирелгән срокларны үтәмәве;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогын яисә тәртибен үтәмәү;

8) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору;

9) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмавы яисә дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.3. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять Министрлыкның җитәкчесенә язма рәвештә кәгазь чыганакта почта аша яисә гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә, электрон рәвештә, шулай ук күпфункцияле үзәк аша бирелә.

Министрлык җитәкчесенең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына язма рәвештә кәгазь чыганакта почта аша, шулай ук электрон рәвештә бирелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять күпфункцияле үзәк директорына язма рәвештә кәгазь чыганакта почта аша яисә гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә, шулай ук электрон рәвештә бирелә.

Күпфункцияле үзәкнең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына язма рәвештә кәгазь чыганакта почта аша яисә гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә, шулай ук электрон рәвештә бирелә.

5.4. Шикаять гариза бирүче вәкиле аша тапшырылганда, аның гариза бирүче исеменнән гамәл кылырга вәкаләтләре барлыгын раслый торган документ та тапшырыла. Мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылырга вәкаләтләре барлыгын раслый торган документ сыйфатында түбәндәгеләр тапшырылырга мөмкин:

1) Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә (физик затлар өчен);

2) гариза бирүче җитәкчесе яисә әлеге җитәкче тарафыннан вәкаләтләр бирелгән зат тарафыннан кул куелган, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә (юридик затлар өчен);

3) физик затны әлеге вазыйфага билгеләп кую аңа гариза бирүче исеменнән ышанычнамәдән башка эш йөртү хокукы бирә торган вазыйфага билгеләп кую (сайлап кую) турында карарның яки вазыйфага билгеләп кую турында боерыкның күчермәсе.

5.5. Язма рәвештә бирелгән шикаятьне кабул итү Министрлык тарафыннан эш көнендә башкарыла.

Шикаятьне шәхсән кабул итү барышында тапшырганда, гариза бирүче Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенең шәхесен таныклый торган документны күрсәтә.

5.6. Электрон рәвештә шикаять гариза бирүче тарафыннан түбәндәгеләр ярдәмендә тапшырылырга мөмкин:

1) Министрлыкның рәсми сайты;

2) Республика порталы;

3) Бердәм портал;

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә чыгарылган карарларына һәм кылынган гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – судка кадәр шикаять бирү системасы) порталы.

5.7. Шикаять электрон рәвештә тапшырылган очракта, әлеге Административ регламентның 5.4 пунктында күрсәтелгән документлар электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшырылырга мөмкин, аның формасы Россия Федерациясе законнарында каралган, шул ук вакытта гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документ таләп ителми.

5.8. Шикаять алынганнан соң күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк һәм Министрлык арасында хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, шикаять кергән көннән киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, аның Министрлыкка тапшырылуын тәэмин итә.

5.9. Шикаятьтә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган Министрлыкның атамасы, Министрлык җитәкчесенең һәм (яисә) Министрлыкның хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм (яисә) вазыйфасы, күпфункцияле үзәкнең атамасы һәм (яисә) аның җитәкчесенең һәм (яисә) хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гариза бирүче – физик затның (шәхси эшкуарның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаять электрон документ рәвешендә бирелгән очракта – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гариза бирүчегә җавап электрон документ рәвешендә җибәрелергә тиеш булганда – электрон почта адресы, җавап язма рәвештә җибәрелергә тиеш булганда – почта адресы (шикаять судка кадәр шикаять бирү системасы аша җибәрелгән очрактан тыш); гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, элемтә өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрү өчен электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы (шикаять судка кадәр шикаять бирү системасы аша җибәрелгән очрактан тыш);

3) Министрлыкның, аның җитәкчесенең яисә вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең яисә хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның җитәкчесенең яисә вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең яисә хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләреннән (гамәл кылмауларыннан) ризасызлыгына нигез булган дәлилләр. Гариза бирүче тарафыннан үз

дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта), яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.10. Министрлыкка карауга тапшырылган шикаять, ул тапшырылган көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлә һәм шикаятьне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан теркәлгән көненнән 15 эш көне, ә Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә әлеге хатларны төзү өчен бирелгән срокларны үтәмәвенә шикаять бирелгән очракта – теркәгән көненнән биш эш көне дәвамында карап тикшерелә.

5.11. Шикаятьне карап тикшерүне туктату өчен нигезләр юк.

5.12. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык акт рәвешендә түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү турында, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хәреф хаталарын һәм (яисә) ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, әлеге Административ регламент нигезендә түләү каралмаган акчаны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту турында.

5.13. Әлеге Административ регламентның 5.12 пунктында күрсәтелгән карарны кабул итү көненнән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм аның теләге буенча электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә. Шикаять судка кадәр шикаять бирү системасы аша җибәрелгән очракта, гариза бирүчегә җавап шулай ук әлеге система аша җибәрелә.

5.14. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки тикшерү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының 5.63 статьясында каралган административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, әлеге Административ регламентның 5.3 пункты нигезендә шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.15. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бирелгән җавапта түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) дәүләт хезмәтен күрсәткән, шикаятьне карап тикшергән органның атамасы, шикаять буенча карар кабул иткән вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) карарына яки гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган вазыйфаи зат турындагы мәгълүматларны да кертеп, карарның номеры, датасы, кабул ителгән урыны;

3) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) яисә атамасы;

4) шикаять буенча карар кабул итү өчен нигезләр;

5) шикаять буенча кабул ителгән карар;

6) шикаять нигезле дип табылган очракта, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны тиз арада бетерү максатларында Министрлык үз гамәлләре турында мәгълүмат җибәрә һәм аңа уңайсызлыклар китергән өчен гариза бирүчедән гафу үтенә, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен киләчәктә аңа нинди гамәлләр кылырга кирәклеге турында мәгълүмат бирә;

7) шикаять буенча кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүматлар.

5.16. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бирелгән җавапка шикаятьне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат имза куя.

5.17. Гариза бирүче шикаятьне карап тикшерү барышында Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән карардан риза булмаган очракта, яки алар тарафыннан карар кабул ителмәсә, гариза бирүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать итәргә яки кабул ителгән карарга суд аша Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

5.18. Шикаятьне бирү һәм карап тикшерү тәртибе турындагы мәгълүматны түбәндәге ысуллар белән алырга була:

1) Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бииаларында урнаштырылган, шикаятьне бирү һәм карап тикшерү тәртибе турында визуаль һәм текст рәвешендә мәгълүматлар булган мәгълүмати элмә такталардан;

2) «Интернет» челтәреннән:

Министрлыкның рәсми сайтында;

Республика порталында;

Бердәм порталда;

3) Министрлыкка телдән (телефон аша яки шәхсән) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән, Министрлыкның рәсми сайты аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

5.19. Министрлык шикаятьне канәгатьләндерүдән түбәндәге очракларда баш тарта:

1) шул ук предмет һәм шул ук нигезләр буенча шикаятькә карата законлы көченә кергән суд, арбитраж суды карары булганда;

2) шикаять Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә вәкаләтләре расланмаган зат тарафыннан бирелгәндә;

3) шул ук гариза бирүчегә карата һәм шикаятьтәге шул ук предметка карата элегрәк кабул ителгән карар булганда.

5.20. Министрлык түбәндәге очракларда шикаятьне җавапсыз калдыра (бу хакта гариза бирүчегә билгеләнгән тәртиптә хәбәр итә):

1) шикаятьтә цензурасыз яки мыскыллы гыйбарәләр, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә янаулар булса;

2) шикаять текстын, мөрәҗәгать итүченең фамилиясен яки почта адресын уку мөмкинлеге булмаса.

5.21. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында дәлилле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.22. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә җайга салына:

210-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның вазыйфаи затлары, федераль дәүләт хезмәткәрләре, Россия Федерациясе дәүләт бюджеттан тыш фондлары вазыйфаи затлары, федераль законнар нигезендә билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү вәкаләтләре бирелгән дәүләт корпорацияләре һәм аларның вазыйфаи затлары, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясы 11 кисәгендә каралган оешмалар һәм аларның хезмәткәрләре, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре һәм аларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү һәм аларны карап тикшерү тәртибе хакында» 2012 елның 16 августындагы 840 номерлы карары.

Шикаять бирү һәм аны карап тикшерү тәртибе турында мәгълүмат Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтында, Республика порталында, Бердәм порталда урнаштырыла, шулай ук телефон аша һәм (яисә) шәхсән кабул иткәндә телдән яки гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) тарафыннан күрсәтелгән адрес буенча почта аша язма рәвештә җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлыгы
тарафыннан «Урман фонды
җирләре чикләрендә урман
кишәрлекләрен сатулар
уздырмыйча арендага бирү»
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
урман хуҗалыгы министрына
____________________________
(Ф.И.Аи.)

**Урман кишәрлеген арендага бирү/урман кишәрлеген арендалауның яңа шартнамәсен төзү турында (тиешлесенең астына сызарга)**
**ГАРИЗА**

_____ елның «___» ______________

1. Юридик затның атамасы, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)______________________________________________________
2. Шәхесен таныклаучы документның реквизитлары (физик затлар өчен):
сериясе ____ №____ ___ елның «___» _________ _________________бирелде.
(кайчан) (кем тарафыннан)
3. Физик затның яшәү урыны (вакытлыча яшәү) адресы:
____________________________________________________________
4. Почта адресы__________________________________________________
5. Элемтә өчен телефон_________факс ________ e-mail:_________________
6. Банк реквизитлары*:
КПП ___________________________________
Исәп-хисап счеты________________________ ________________________
К/с ________________________________________ БИК___________________

Миңа түбәндәге адреста: Татарстан Республикасы________муниципаль районындагы__________урманчылыгының________участок урманчылыгы, _____номерлы кварталында урнашкан урман кишәрлеген арендага бирүегезне (урман кишәрлеген арендалауның яңа шартнамәсен төзүне) сорыйм.
Урман кишәрлегенең мәйданы ______________ га
Урманнардан файдалану срогы ____________________ ел**
Файдалану төре (төрләре) __________________________________**
Файдалану максаты ________________________________________**

Урман кишәрлегенең кадастр номеры________________________________

Урман кишәрлеген проектлау документларын раслау турында карарның реквизитлары, сорала торган урман кишәрлеге әлеге карар нигезендә төзелгән яисә чикләре ачыкланган очракта _______________________**

Элек төзелгән аренда шартнамәсенең номеры һәм аңа кул куелу датасы (шул исәптән аренда шартнамәсен дәүләт теркәвенә алу датасы) ____________***

Элек төзелгән аренда шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты_________ лет***

Элек төзелгән аренда шартнамәсе буенча урманнардан файдалану төре _________***

Яңа аренда шартнамәсенең гамәлдә булуы фаразланган срок _____ лет***

Кушымта: ____________________________________

____________________________________

____________________________________

____________________________________

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен тапшыруны сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталындагы шәхси кабинетка

☐ кәгазь чыганакта шәхсән

☐ кәгазь чыганакта почта аша

_______________________________ (Юридик затның җитәкчесе, физик зат)

________________/____________/ (имзасы, ФИАи (соңгысы – булган очракта)

М.У.
(булган очракта)

______________

Кушымталар:

* Бары тик юридик затлар тарафыннан гына тутырыла.

** Бары тик урман кишәрлеген арендага бирү турында гариза тапшырганда гына тутырыла.

*** Бары тик урман кишәрлеген арендалауның яңа шартнамәсен төзегәндә генә тутырыла.

____________

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлыгы
тарафыннан «Урман фонды
җирләре чикләрендә урман
кишәрлекләрен сатулар
уздырмыйча арендага бирү» дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына
2 нче кушымта

Форма

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә
ризалык

20___ елның «___» ________

Мин, ____________________________________________________________
Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта)
____________________________ ________ серияле________ номерлы,
(шәхесен таныклаучы документның төре)
__________________________________________________________________,
(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
____________________________________________адресы буенча яшәүче,

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан минем шәхси белешмәләремне тикшерүгә ризалык бирәм һәм әлеге ризалыкны биргәндә үз ихтыярымда һәм үз мәнфәгатьләремдә эш йөртүемне раслыйм. Әлеге ризалык минем тарафтан «Урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен сатулар уздырмыйча арендага бирү» дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында бирелә һәм түбәндәге мәгълүматларга кагыла:

фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), туган вакыты, яшәү урыны (вакытлыча яшәү урыны) адресы, почта адресы, паспорт белешмәләре, элемтә өчен телефон, электрон почта адресы.

Әлеге ризалык югарыда күрсәтелгән максатка ирешү өчен тиешле һәм кирәкле минем шәхси белешмәләремә бәйле теләсә кайсы гамәлләр кылу, минем шәхси белешмәләремне җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), алардан файдалану, тарату, шәхесенә кагылышлы үзенчәлекләрен бетерү, гамәлен туктату, юкка чыгару, шулай ук федераль законнар нигезендә башка гамәлләр кылу өчен бирелә.

Минем тарафтан бирелгән шәхси белешмәләр законсыз файдаланылган очракта әлеге ризалык минем язма гаризам нигезендә кире алына.

Әлеге ризалык 20____ елның «___» ________ннән урман кишәрлеген арендалау шартнамәсенең срогы беткәнчегә кадәр гамәлдә.

___________________________/__________________________
Ризалык биргән затның Ф.И.Аи. (соңгысы булган очракта), имзасы

___________